**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«23» август 2023 ел № 30/1

**«Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү турында» Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының 2012 елның 05 майдагы 7/2 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 январендагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының 2012 елның 05 майдагы 7/2 номерлы карары белән расланган «ТР Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Мәгълүматка керү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары һәм ведомство карамагындагы оешмалар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә тәэмин ителә.»;

б) 9 бүлектә:
1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«1. Җирле үзидарә органнары мәгълүматны урнаштыру өчен интернет челтәрен куллана, анда Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә туры китереп төзелгән һәм мәгълүмат кулланучы тарафыннан сорау җибәрелергә һәм соралган мәгълүмат алынырга мөмкин булган электрон почта адреслары күрсәтелгән рәсми сайт булдырыла. Ведомство карамагындагы оешмалар җирле үзидарә органнары карары буенча, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми сайтлар булдыралар. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары ведомство карамагындагы оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүмат Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин»;

түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктын өстәргә:

«1.1. Җирле үзидарә органнары һәм алар карамагындагы оешмалар интернет челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр булдыралар. Ведомство карамагындагы оешмалар, эшчәнлек өлкәсе үзенчәлекләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары белән килешү буенча, үз эшчәнлекләре турында мәгълүматны интернет челтәрендә урнаштыру өчен рәсми битләр булдырмаска мөмкин. Интернет челтәрендәге әлеге битләр күрсәткечләре белән рәсми битләр турында мәгълүмат җирле үзидарә органы яки ведомство карамагындагы оешманың рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге бүлекнең 1 һәм 1.1 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматка чикләнмәгән затлар даирәсе керү хокукын тәэмин итү максатыннан, кулланучылар өчен мәгълүмат булган урыннарда (җирле үзидарә органнары, муниципаль китапханәләр биналарында, башка урыннарда) интернет челтәренә тоташу пунктлары булдырыла.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кулланучыларның әлеге бүлекнең 1 һәм 1.1 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматка керү хокукын тәэмин итү максатыннан, җирле үзидарә органнары әлеге мәгълүматны Россия Федерациясе законнары нигезендә яклау буенча чаралар күрә »;

в) 11 бүлекнең 10 пунктында «интернет челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алыштырырга;

г) 14 бүлекнең беренче абзацында «җирле үзидарә органнары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм ведомство карамагындагы оешмалар» сүзләренә алыштырырга, «хезмәткәрләр» сүзеннән соң «ведомство карамагындагы оешмалар хезмәткәрләре,» сүзләрен өстәргә;

д) 2 кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Сафина